**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 5 июль №54

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2016 елның 9 февралендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.3 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9)Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданины муниципаль хезмәттә булу хокукын билгеләүче Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданствосы) туктату турында муниципаль хезмәткәргә шул турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданины муниципаль хезмәттә булу хокукын билгеләүче Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданствосы) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында йә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы чит ил документы яисә башка документ алу турында муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән соң йә гражданның чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы документны яисә башка документны алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

5.5 пунктының 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Диспансерлаштыру узу тәртибе, мондый авырулар исемлеге һәм медицина оешмасын төзү рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә;»

5.5 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6)чит ил гражданының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы (подданствосы) туктатылса;»;

5.5 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7)чит ил гражданлыгы (подданствосы) булу яисә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

12.1 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башлыгы урынбасары Л.Т.Хантимировка йөкләргә.

**Апас муниципаль районы**
**Башлыгы**
**Апас муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Хисамутдинов Р.Ф.**